СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 24 февраленнән — № 47-156

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 28 декабрендәге 17-53 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында», Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәгә 28.12.2021 № 17-53 (Зирекле авыл җирлеге Советы карары редакциясендә 19.12.2023 № 34-125; 1.03.2024 № 37-131; 25.11.2024 № 43-147;) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне:

1.1. 3.18. пунктның 1 пунктчасы Нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) контроль чара актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотыла торган затка, аларны бетерүнең тиешле срокларын күрсәтеп, мәҗбүри таләпләрне, шулай ук федераль законда контроль рәвеше турында каралган башка чараларны ачыклау турында күрсәтмә бирергә;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге советы рәисенең законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы                    Җ.Г. Гайфетдинов